СОВЕТ СИЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГОМУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д. 1, с.Смак-Корса,
Арский муниципальный район, 422025

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СЕҖЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Мәктәп урамы, 1 йорт, Курса Почмак авылы,
Арча муниципаль районы, 422025

Тел. (84366)53-2-36, факс (84366)53-2-36. E-mail: Sizin.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**25 октябрь 2021 ел** **№ 13**

**Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Сеҗе авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Сеҗе авылында Сеҗе авылы, Мәктәп урамы, 25 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2021 елның 18 ноябренә 10 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Сеҗе авылында Сеҗе авылы, Мәктәп урамы, 25 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2021 елның 18 ноябренә 15 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1нче этап: Вахитов, Мәктәп урамнарында яшәүчеләр.

2нче этап: Тынычлык урамында яшәүчеләр.

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Сеҗе авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган

кешегә, түләү күләме 275 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан ,1нче группа инвалидлардан һәм 80 яшьтән узган гражданнардан тыш, 550 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, автоматлар, контакторлар сатып алу һәм урнаштыру;

- Мир урамында Кесмәс елгасы аша күпер төзү һәм материаллар сатып алу (2 этап)

-Мәктәп урамыннан 29 нчы йортка кадәр, асфальт юлдан Мәктәп урамының 30 нчы йортка кадәр, Вахитов урамында 7дән 6 нчы йортка кадәр, асфальт юлдан Мир урамы буенча юл-урам челтәренең автомобиль юлларына вак таш җәю;

- асфальт юлдан Школьная урамындагы 24 нче йортка кадәр юл полотносына нигез салу һәм вак таш җәю;

- зиратны карап тоту өчен бензин триммеры (бензокосилка) сатып алу;

- зиратны карап тоту өчен бензопила сатып алу;

- МТЗ 82.1 тракторына асылмалы җиһазлар сатып алуны финанслашу (борылышлы гидравлик отвал, үзбушаткыч тагылма, чапкыч, фронталь эленмәле төягеч сәнәге, чүмечле фронталь эленмәле төягеч);

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

5. Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Сеҗе авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Сеҗе авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына РТ, Арча районы,Сеҗе авылы,Мәктәп урамы,25 нче йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сеҗе авыл җирлеге башлыгы Р.В.Хәмидуллин